Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Олы Солтан авыл җирлеге Советы

**КАРАР № 14**

Олы Солтан авылы 27 июнь, 2019 ел

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Солтан авыл җирлегенең генераль планын раслау турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 24 маддәсенә, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Солтан авыл җирлеге Уставына ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Солтан авыл җирлегенең генераль планы проектына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 14 июнендәге 10-53/7122 номерлы уңай бәяләмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Солтан авыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Солтан авыл җирлегенең генераль планын кадастр номеры 16:34:091101:98, мәйданы 2531кв.м. һәм кадастр номеры 16:34:091101:295, мәйданы 5646 кв.м. булган җир кишәрлекләренең АЗС һәм килү юллары урнаштыру өчен сәнәгать җирләре категориясенә алга таба күчерү белән урнашуларын исәпкә алып расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Солтан авыл җирлегенең түбәндәге адрес буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Олы Солтан авылы, Р.Шәрәфиев урамы, 12 йорт һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Олы Солтан авыл җирлеге башлыгы Р.Р.Сөнгатуллин

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН РЫБНО-СЛОБОДСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТ БОЛЬШЕСАЛТАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ИНН 1634000725
ОЛЫ СОЛТАН АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ